ШИМБӘ
6
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 30 (6752)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР СТАРЫЙ ОСКОЛ, ИЗЮМ ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1. 5 нче февральдә безнең гаскәрләр бик каты сугыштан соң СТАРЫЙ ОСКОЛ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар. Дошманның чолганып алынган гарнизоны юк ителде һәм бер өлеше плен алынды.

2. Украинада безнең гаскәрләр ИЗЮМ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

МОСКВА, КРЕМЛЬ, ИПТӘШ СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Фронтка ярдәмне көчәйтү турында, явыз немец-фашист басып алучыларны кыру средстволарын һәм коралларын эшләп чыгаруны арттыру турында Сезнең даһи күрсәтмәләрегез белән барып, бөек ватан сугышы фронтларында героик Кызыл Армиянең уңышлы һөҗүме белән рухланып, Ижевск шәһәренең хезмәт ияләре үзләренең саклык акчаларыннан танклар һәм самолетлар төзелешенә 16 миллион сум җыйдылар. Шушы суммадан 12 миллион сумы «Ижевск эшчесе» исемле танклар колоннасы төзелешенә җыелды. Акча җыю дәвам итә һәм ул совет патриотлыгының, ватаныбызга һәм Сезгә, сөекле Иосиф Виссарионович, бернәрсә белән дә тиңләштермәслек һәм бетмәслек мәхәббәтнең ачык демонстрациясе төсендә бара.

Ижевск эшчеләре ватан сугышының беренче көннәреннән үк ватаныбызның хәрби куәтен ныгыту өстендә намус белән һәм үз-үзләрен аямыйча эшлиләр, үзләренең фронт каршындагы бурычларын төгәл үтиләр. Безнең стахановча хезмәтебезгә безнең суммаларга ясалган дәһшәтле танклар һәм самолетлар өстәлсен.

Без ышанабыз, безнең сугыш машиналары сталинчы очучыларның һәм танкистларның оста кулларында һавада да, җирдә дә, гитлерчы бандитларны тар-мар итәрләр.

Сезгә, сөекле Иосиф Виссарионович, ватаныбыз халыкларының шатлыгы өчен һәм дошманнарга дәһшәт өчен озак һәм озак елларга көч һәм сәламәтлек телибез.

ВКП(б) ның Ижевск шәһәр комитеты секретаре КОЗЛОВ.

ИЖЕВСК ШӘҺӘРЕ.

ВКП(б) ның Ижевск шәһәр комитеты секретаре иптәш КОЗЛОВКА

«Ижевск эшчесе» исемле танклар колоннасы һәм самолетлар төзелешенә 16 миллион сум акча җыйган Ижевск хезмәт ияләренә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Совет Социалистик Республикалар Союзы кораллы көчләренең Верховный Баш Командующие Гали җәнаб Иосиф В. Сталинга

МОСКВА.

Америка Кушма Штатлары кораллы көчләренең баш командующие сыйфатында мин Сезнең гаскәрләрнең Сталинград янында Сезнең верховный командалыгыгызда ирешкән гүзәл җиңүләре белән Сезне котлыйм. Шәһәр өчен йөз алтмыш ике көн дәвам иткән эпик көрәш, Сезнең исемегезне мәңгелеккә данлыклы иткән көрәш, шулай ук бүген барлык америкалылар тарафыннан бәйрәм ителә торган хәл иткеч нәтиҗә нацизмга һәм аның иярченнәренә каршы берләшкән халыкларның бу сугышында иң гүзәл сәхифәләрнең берсе булыр. Фронтта Сезнең гаскәрләрнең командирлары һәм сугышчылары, заводларда һәм кырларда эшләп аларга ярдәм иткән ирләр һәм хатын-кызлар үз илләренең коралын дан белән каплау өчен генә түгел, бәлки, үзләреннән үрнәк күрсәтеп, гомуми дошманны тәмам җиңүгә һәм аның һичбер сүзсез капитуляциясенә ирешү юлында барлык берләшкән милләтләр арасында үзләренең бөтен энергияләрен бирүгә булган яңа омтылышны тудыру өчен берләштеләр.

ФРАНКЛИН Д. РУЗВЕЛЬТ.

ВАШИНГТОН, 5 февраль, 1943 ел.

Америка Кушма Штатлары кораллы көчләре Баш Командующие Франклин Д. Рузвельт әфәндегә

АК ЙОРТ, ВАШИНГТОН.

Совет гаскәрләренең Сталинград янында җиңүләре уңае белән Сезнең котлавыгыз өчен рәхмәт әйтәм.

Кушма Штатлар, Бөек Британия һәм Советлар Союзы кораллы көчләренең берләштерелгән сугыш хәрәкәтләре тиз араларда гомуми дошманыбыз өстеннән җиңүгә китерерләр дип ышаныч белдерәм.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль,
6 февраль, 1943 ел.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Үзәк фронт). Габбас Исмагыйловның ватаныбызның дошманнарына каршы батырларча сугышуы беренче тапкыр гына түгел инде. Ул Царицын янында сугышты, врангельчыларга каршы сугышты, басмачыларга каршы сугышты. Хәзер Габбас Исмагыйлов оста снайпер. Аз гына вакыт эчендә ул 81 фашистны юк итте.

М. Беркович фотосы.
(ТАСС фотохроникасы)

Воронеждан көнбатыштарак

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ, 3 февраль. **(ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән).** Сугыш омтылышы белән рухланган безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга баралар. Күп кенә участокларда безнең алга баруыбызны туктатырга омтылучы дошманга каршы бик каты сугышлар бара. Безнең подразделениеләр оста итеп әйләнеп үтү маневрлары ясап, немецлар урнашкан урыннарга бәреп керәләр, дошманның юлларын кисәләр, җанлы көчләрен һәм техникасын юк итәләр.

Күптән түгел гитлерчылардан азат ителгән Касторноега, Долгаяга, Советскоега бара торган юллар меңнәрчә немец солдатларының һәм офицерларының үле гәүдәләре белән һәм дошманның күп төрле сугыш техникасы белән тулган. Тимер юл узелларына һәм станцияләренә орудиеләр, танклар, сугыш припаслары, амунициялләр, азык һәм башка сугыш милекләре төялгән эшелоннар тулган. Безнең гаскәрләрнең ударлары астында чигенгән чакта немецлар ташлап калдырган әйберләрне санап бетерергә мөмкин түгел. Кар көртләрендә берничә транспорт колоннасы тукталып калган. Шулардан берсе 600 дән артык йөк машинасыннан һәм җиңел автомобильләрдән тора. Шунда ук фашистлар бик күп санда бөтенләй төзек булган пушкалар ташлап калдырганнар. Кая гына карама, һәркайда да җимерелгән орудиеләр, транспортерлар, өем-өем сугыш припаслары, меңнәрчә снарядлар, гаять күп санда миналар, гранаталар һәм патроннар тутырылган ящиклар.

Танклар дошманга каршы геройларча сугышалар. Безнең автоматчиклар десанты утырган машиналарыбыз дошман тылына үтеп чыктылар һәм кинәт удар ясап, әһәмиятле бер тимер юл станциясен алдылар. Танкистлар алга таба шул кадәр көчле омтылыш белән бардылар ки, хәтта дошман алар юлында тора торган бер күперне дә шартлатырга өлгермәде.

Безнең танклар подразделениеләре, дошманның юлларына кинәт һөҗүмнәр ясап, аны зур югалтуларга дучар итәләр. Бер пунктта немецлар яңа позициягә күчәргә әзерләнеп, ашыгыч рәвештә үзләренең милекләрен төяп торалар иде. Анда күп тонна күтәрә торган 124 автомобиль төялергә тиеш иде. Безнең танклар группасы кинәт кенә бу колоннага якынлашты һәм барган җиреннән аңа атака ясады. 150 дән артык гитлерчылар кулларын күтәрделәр һәм бөтен милекләре һәм машиналары белән берлектә плен алындылар. Икенче бер урында танкистлар—Сучеров, Чернега һәм Алексеев иптәшләр, берничә йөз фашистны пленга бирелергә мәҗбүр иттеләр. Бу хәл халык яши торган бер зур пунктның читендә булды. Фашистлар, подвалларга һәм таш йортларга яшеренеп, көчле тоткарлау уты ачтылар. Сучеров, Чернега һәм Алексеев иптәшләр алга таба үтеп чыктылар һәм бер кешене плен алып, аны немецлар урнашкан урынга җибәрделәр һәм аларга хәзер үк коралларын ташларга тәкъдим итәргә куштылар. Немецлар җавапны озакка суздылар. Шуннан соң танкистлар дошманның ут точкаларына берничә залп җибәрделәр. Бу хәл гитлерчыларның телен ачты. Озакламый бер төркем дошман солдатлары һәм офицерлары, ак флаг тотып, мәйданга чыктылар һәм коралларын ташладылар.

Өлкән лейтенант Скальников командалыгындагы танк экипажы батырларча һәм куркусыз сугышты. Ул бер тимер юл станциясенә беренчеләрнең берсе булып бәреп керде һәм, туры атып, көнбатышка таба китеп баручы бер паровозны җимерде. Юл тыгылган булып чыкты һәм станциядә булган барлык эшелоннар безнең кулга күчте.

Станцияне саклаучы гитлерчылар барысы да каты сугыш нәтиҗәсендә кырып ташландылар. Майор Рыленков һәм капитан Ткачев станция өстенә кызыл байрак күтәрделәр.

Дошманны авыр югалтуларга дучар итүче танк подразделениеләре артыннан безнең пехота подразделениеләре бара. Һөҗүм темпы сәгать саен арта. Совет сугышчылары дошманга өзлексез атакалар ясыйлар һәм фашистларны кыралар.

И. ГРИБОВ.

Совет информбюросыннан

5 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга баруларында дәвам иттеләр. Н-че часть ике сәгать дәвам иткән сугышта немецларның бер батальон пехотасын тар-мар итте һәм дошманның 3 танкысын юк итте. Икенче бер участокта безнең хәрәкәттәге отрядларыбыз халык яши торган бер зур пунктны алдылар. 2 бронемашина, 4 орудие, шулардан 2 авыр орудие, бер азык склады һәм бер әйбер склады кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Красный Лиман районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары гитлерчыларның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Икенче бер участокта немецлар, резервлар китереп, сугышка бик күп танклар һәм ике полкка якын пехота керттеләр. Безнең частьлар, авиация ярдәме белән, дошманга авыр удар ясадылар, аны алып ташладылар һәм алга киттеләр. Немецларның 18 танкысы һәм 500 гә якын солдат һәм офицерлары юк ителде. Һава сугышларында совет очучылары дошманның 8 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Купянск районында Н-че часть уңайлы бер чик өчен булган сугышта немецларның ике ротага якын пехотасын, 3 танкысын һәм бер артиллерия батареясын юк итте. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары ике көн эчендә 1.485 дошман солдатын һәм офицерын плен алдылар. 54 орудие, 52 миномет, 75 пулемет, 6 радиостанция, һәртөрле 28 склад һәм башка төрле күп сугыш материаллары кулга төшерелде. Башка участокларда безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

* * *

Закавказье фронтында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Бер участокта совет танкистлары дошман обороnasына эчкәрегә үтеп керделәр һәм бер батальонга якын немецлар пехотасын кырып ташладылар. Соңгы сугышларда Н-че берләшмә частьлары 19 танк, 68 орудие, шулардан эре калибрлы 48 орудие, 30 тягач, 149 автомашина, 446 велосипед, бер сугыш припаслары склады һәм 2 азык склады кулга төшерделәр.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецларның артиллерия һәм автомашиналар төялгән бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. Паровоз, 2 вагон һәм 8 платформа җимерелгән. Һәлакәт вакытында 20 немец солдаты үлгән. Икенче бер отрядның партизаннары январь ахырында халык яши торган бер пунктта кинәт немецлар гарнизонына атака ясаганнар. Ике арада башланып киткән сугышта совет патриотлары 40 гитлерчыны юк иткәннәр һәм 2 пулемет, 15 винтовка, 10.000 патрон кулга төшергәннәр.

* * *

Хәзерге вакытта Германиядәге һәм ул басып алган илләрдәге төрмәләрдә һәм солдатларны яба торган концентрация лагерьларында күп меңнәрчә немец солдатлары бар. Торгау-Эльбадагы хәрби төрмәдә 3.000 нән артык тоткын ята. Трауденц төрмәсенә ай саен хәрби судлар тарафыннан хөкем ителгән меңләп немец солдатлары килеп тора. Боларның күбесе Совет—Германия фронтында хәрәкәт итүче гаскәри частьлардан китерелгән солдатлар. Аларның күпчелеге «армияне какшаткан өчен», «дошманның кораллы көчләрен мактаган өчен», «сугыш кырында йомшаклык күрсәткән өчен һәм коралын югалткан өчен», «үз-үзен имгәткән өчен» һәм башка шундыйлар өчен хөкем ителгәннәр.

5 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче февральдә безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң **Старый Оскол** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар. Дошманның чолганып алынган гарнизоны юк ителде һәм бер өлеше плен алынды. Старый Осколдан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр район үзәкләре **Боброво-Дворскоены** һәм **Скородноены** алдылар.

* * *

Украинада безнең гаскәрләр **Изюм** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук район үзәге һәм тимер юл станциясе **Великий Бурлукны**, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Яманы**, район үзәге **Ольховатканы** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып баруны дәвам иттерделәр.

4 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 3 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер тимер юл эшелонын җимерделәр һәм бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Н-че кавалерия часте 2 паровоз, 300 вагон, 150 автомашина, 3 танкетка, 100 мотоцикл һәм 2 азык склады кулга төшерде. Крыловская станциясен алган чакта безнең сугышчылар бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Шулар арасында танклар төялгән бер тимер юл эшелоны һәм азык төялгән бер эшелон бар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр, алга таба барып, халык яши торган берничә пунктны алдылар, 400 гитлерчыны, дошманның 4 танкысын, 3 танкеткасын юк иттеләр һәм 175 кешене плен алдылар.

* * *

Купянск районында безнең гаскәрләр алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 8 авыр орудие һәм 2 ашлык склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че гвардия часте сугышчылары немецларның 6 танкысын, 3 бронемашинасын, 20 автомашинасын, 3 паровозын һәм 45 вагонын кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта Н-че часть венгерларның бер пехота полкын тар-мар итте. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта майор **Сычевой**, бер группа автоматчиклар белән бергәләп, бер авылга ныгып урнашкан дошманның тылына үтеп чыкты. Безнең автоматчикларның кинәт атакасыннан каушап калган немецлар, 30 орудиеләрен, күп пулеметларын, винтовкаларын һәм сугыш припасларын калдырып, качтылар.

* * *

Смоленск партизаннарының берничә отряды 15 нче январьдан 27 сенә кадәр булган вакыт эчендә дошманның 15 эшелонын юлдан чыгарганнар. 13 паровоз һәм 200 гә якын вагон җимерелгән. Шул ук вакыт эчендә совет патриотлары 6 күперне, берничә урыннан тимер юлны шартлатканнар һәм 17 километр телефон-теле-граф чыбыгын кисеп алганнар.

* * *

Немецларның 297 нче пехота дивизиясенең плен алынган командиры генерал-майор Мориц Дреббер болай диде: «Руслар тарафыннан немец гаскәрләрен чолгап алу белән тәмам булган һөҗүмне туктатырга мөмкин булмады. Сталинград безнең барлык резервларыбызны ашап бетерде. 10 нчы январьда Сталинград янында чолганып алынган безнең гаскәрләргә каршы русларның хәлиткеч һөҗүме башланды. Хәл көннән-көн начарлана барды. Руслар һәммә яктан да безнең частьларны оборона линиясеннән бәреп чыгардылар һәм аларны көнчыгышка таба кысрыкладылар. 25 нче январьда иртә белән, барлык калибрлардагы орудиеләрдән көчле артиллерия әзерлеге үткәргәннән соң, руслар пехотасы, танклар ярдәме белән, атака башлады. Русларның танклары сул флангны өзделәр һәм пехота отрядлары белән, шулай ук танкларга утырган автоматчиклар группалары белән бергәләп, оборонага эчкәре бәреп керделәр һәм дивизиянең частьларын бүлгәләделәр. Артиллерия полкы командиры полковник Фухт үзенең штабы белән берлектә пленга эләкте. 297 нче дивизиянең 523 нче полкы командиры үзенең полкы белән берлектә аерылып калды һәм бирелде. Русларның танклары дивизия штабы урнашкан йортка орудиеләрдән һәм пулеметлардан ата башладылар. Куркыныч. бик зур иде. Мин бер карарга килдем һәм дивизиянең калдыклары белән берлектә пленга бирелдем. Шулай итеп, немецларның 297 нче пехота дивизиясе үзенең яшәвен тәмам итте. Аның артыннан Сталинград районында чолганып алынган башка күп дивизияләр дә үзләренең яшәүләрен туктаттылар. Безнең югалтулар турында сөйләп тә торасы юк. Бу югалтулар гаять зур. Без үзебездә булган бөтен нәрсәне югалттык».

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсенең Пасеково авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Кызыл Армиянең ударлары астында чигенгән чакта немецлар авылда хоточкыч җинаять эшләделәр. Гитлерчы бандитлар базларга һәм подвалларга яшеренгән кешеләрне өстерәп чыгардылар һәм аттылар. Палачлар И. Колесниковны, Н. Колесникованы, аның 6 яшьлек кызын, И. Задорожныйны һәм башка күп кешеләрне үтерделәр. Фашист ерткычлар колхозчы Бутованың йортын яндырдылар. Ул янгынны сүндерә башлагач, фашистлар аны атып үтерделәр». Актка өлкән лейтенант А. Леонтьев, гвардияче кызылармеецлар Ф. Сахнов, Д. Калинин; Пасеково авылы кешеләреннән В. Ахременко, Е. Задорожная һәм башкалар кул куйды.

МАРШАЛНЫҢ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕСЕ БУЛГАН „МАРШАЛ ЙОЛДЫЗЫ" ҺӘМ БЕРЕНЧЕ ДӘРӘҖӘ СУВОРОВ ОРДЕННАРЫ ТАПШЫРУ

Шушы елның 4 нче февралендә, Кремльдә, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш **М. И. Калинин** Советлар Союзы Маршалы иптәш **Г. К. Жуковка** маршалның аерымлык билгесе булган **«Маршал йолдызы»** һәм беренче дәрәҗә **Суворов** ордены тапшырды.

Авиация генерал-полковнигы иптәш **А. А. Новиковка** һәм авиация генерал-лейтенанты иптәш **А. Е. Головановка** иптәш **М. И. Калинин** беренче дәрәҗә **Суворов** орденнары тапшырды.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Воронеж районы). Легендар полководец Чапаевның улы орденлы майор А. В. Чапаев немец оккупантларына каршы оста сугыша. Рәсемдә: А. В. Чапаев (унда) артиллерия батареясының ут позициясе лейтенант комсомолец В. Я. Болошовның идә.
ТАСС фотохроникасы.

Немец оккупантлардан азат ителгән Котельниково шәһәрендә. Рәсемдә: район советы башкарма комитеты бинасына кызыл флаг куялар.
ТАСС фотохроникасы.

Батыр сугышчыларга бәйрәм бүләкләре

ЮТАЗЫ, 4 февраль. (Махсус хәбәрчебездән, телефон буенча). Иптәш Сталинның Кызыл Армиябезне котлау телеграммасы колхозчылар арасында активлыкның яңа күтәрелешен тудырды.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән сугышчыларга җибәрү өчен барлык колхозларда да бүләкләр җыю бара. Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар сугышчыларга тәмле һәм туклыклы азыклар һәм җылы киемнәр җибәрергә ашыгалар. Районның колхозчылары хәзер 24 центнер ит, 600 килограмм бал, 58 килограмм май, 102 баш сарык, 28 каз, 160 тавык, 358 пот ашлык, 918 килограмм сухари, 18.868 литр сөт, 1.793 килограмм киптерелгән бәрәңге, 352 пар бияләй һәм башка бик күп җылы киемнәр тапшырдылар.

Сугышчыларга бүләк җыю Ютазы авыл советына караган колхозларда аеруча яхшы бара. Бу авыл советы буенча 383 килограмм ит, 365 килограмм киптерелгән бәрәңге, 148 килограмм сухари, 150 пот ашлык, 12 сарык, 455 литр сөт һәм башка әйберләр җыелды. Ворошилов исемендәге колхоз членнары 160 килограмм ит, 25 тавык, 18 килограмм сухари, 10 килограмм киптерелгән бәрәңге, 30 пот ашлык, «Игенче № 2» колхозы членнары 120 килограмм ит, 23 тавык, 125 килограмм киптерелгән бәрәңге бүләк иттеләр. «Тугай» колхозы председателе иптәш Фәхретдинов 10 пот ашлык, бер сарык һәм башка әйберләр тапшырды. Ворошилов исемендәге колхоз члены Зиннәт бабай Гыйниятуллин бер сарык, бер пот ашлык, Фәхерниса Кәтиева бер сарык, бер пот ашлык, Арслан Кәтиев бер сарык, 2 пот ашлык бирде. Бәйрәм бүләкләре җыю дәвам итә.

А. ВӘЛИЕВ.

* * *

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә Казан шәһәренең хезмәт ияләре батыр сугышчыларга бәйрәм бүләкләре әзерлиләр.

Бүләкләр алып җибәрү өчен Бауман районында 500 мең сумнан артык акча тупланды. Горпромторг работниклары 100 данә мех жилет бүләк иттеләр. Горпищеторг работниклары 20 мең сум, Военторг работниклары 9.700 сум, хезмәт ияләре депутатларының Бауман район советы башкарма комитеты хезмәткәрләре 9 мең сум акча туплап тапшырдылар. Шәһәрнең барлык районнарында средстволар туплау һәм бүләкләр әзерләү дәвам итә.

БЕР КӨНЛЕК СЕМИНАР

ВКП(б) ның Чистай райкомы башлангыч партоешма секретарьларының бер көнлек семинарларын үткәрде. Анда 32 кеше катнашты. Бу семинарда партия җыелышларына ничек итеп әзерләнү, аларны үткәрү, яшь коммунистлар белән эшләү һәм авылда политик-масса эшләрен сугыш вакыты таләп иткәнчә оештыру мәсьәләләре каралды.

ВКП(б) райкомы мондый семинарларны план буенча һәр ай саен ике тапкыр үткәреп барачак.

Язга отлично әзерләнергә!

Алдынгы колхозда

ЧИСТАЙ, 4 февраль. (Телефон буенча). Вахитов исемендәге колхоз членнары 1942 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы итеп үтәп чыгуда районның башка колхозларына үрнәк булып тора. Бу колхоз районда алдынгы булып санала. Колхозчылар быел мул игеп уңышы яулап алу өчен җитди көрәш алып баралар. Язгы чәчүгә әзерлекне тизрәк төгәлләү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланалар. 48 сабанга, 56 тырмага, 8 чәчү машинасына һәм культиваторга яхшы сыйфатлы итеп ремонт үткәрелгән һәм комиссия тарафыннан кабул ителгән. 120 сука камыты төзәтелде. Чәчү орлыкларын тазарту тулысынча тәмамланган. Аларның тишелеп чыгышы тикшерелгән.

549 гектарда кар тотылган. Басуга 3.700 йөк тирес чыгарылган. 32 центнер көл һәм 35 центнер кош тизәге җыелган. Агротехника укулары план буенча алып барыла, анда 120 кеше йөри. Колхозчылар фронттагыча эшләү өчен «Ударник» колхозын социалистик ярышка чакырдылар.

«Чулпан» колхозы членнары да вахитовчылардан калышмыйлар. Алар язгы чәчүгә әзерлек эшләрен тулысы белән төгәлләделәр. Сабаннарга, тырмаларга, культиваторларга һәм чәчү машиналарына яхшы итеп ремонт ясалган һәм комиссия тарафыннан кабул итеп алынган. Шулай ук дилбегә, постромка баулары да җитәрлек кадәр булдырылган. Ремонтта эшләүчеләрдән Хәбибуллин, Дәүләтшин иптәшләр аеруча зур тырышлык күрсәттеләр.

Атларның торышы яхшы. 250 гектар урынына 300 гектарда кар тотылган, басуга 650 йөк тирес чыгарылган, 8 центнер көл һәм 9 центнер кош тизәге җыелган.

СҮЗДӘН КОНКРЕТ ЭШКӘ КҮЧӘРГӘ ВАКЫТ

Теге яки бу мәсьәлә буенча карар кабул итү эшнең башы гына әле ул. Чыгарылган карарларның тормышка ашырылуын оештыру, аларның үтәлешен тикшерү—җитәкчелекнең оперативлылыгы менә шуннан гыйбарәт.

Кызганычка каршы, Чепья районы җитәкчеләре болай эшләмиләр. Конкрет эшне коры сүзләр һәм вәгъдәләр белән алмаштыралар. Карар кабул итү белән эшне тәгәлләнде дип уйлыйлар. Мәсәлән, атларны яхшы тәрбияләргә кирәклеге турындагы мәсьәлә райком бюросында да, район советы башкарма комитеты утырышында да берничә тапкыр каралган, яхшы гына карарлар чыгарылган. Ләкин аларның үтәлеше тикшерелмәгән. Атлар белән ерткычларча эш итүчеләргә карата тиешле чаралар күрелмәгән. Шуның нәтиҗәсендә 1942 нче елда күп кенә атлар үлгән.

«Кызыл юл» колхозы районда алдынгылардан санала. Аның атларын бик мактыйлар. Ләкин колхозга баргач андагы 115 атның 15 енә камыт һәм ыңгырчак сыктырылган булуы бирелә атларга карашның начар икәнен күрсәтә. 5 нче бригадада «Фазыл тае» дип йөртелә торган атның тоягы кителеп төшкән. Ләкин ат караучы иптәш Шиһабиева да, бригадир да бу хәлне ат аяктан егылгач кына күрәләр. 5 нче бригаданың стена газетасында колхоз члены Булатовның бер атка камыт сыктыруы турында язылган. Газета Булатовка карата тиешле чара күрүне таләп итә. Ләкин, стена газетасының сигналына бер төрле дә игътибар ителми. Атлар белән ерткычларча эш итүче Булатов җавапсыз калдырыла. Ветсанитар Сәгабиев атналар буенча авыру терлекләрне килеп карамый. Ат абзарларында да айга бер генә тапкыр була.

Менә «Крестьянская газета» колхозы. Бу колхозда да атларны яхшы тәрбияләмәүчеләргә чара күрелмәгән. Нәтиҗәдә колхозда 1942 нче елда 15 ат, 1943 нче елда 3 ат үлгән. Колхозчы Хисамиев Шәмәрдән урманына җигеп киткән бер атны яхшылап карамыйча, берничә көн эшләгәч тә, аңа камыт сыктыра. Бик тиз вакыт эчендә атның бер аягы ертылып, капап бетә. Бу турыда район җир бүлегенең өлкән врачы иптәш Шихалинга хәбәр итәләр һәм бер атна буенча, һәр көнне Шихалинны алырга дип район үзәгенә ат җибәрәләр. Шихалин «башка эшләр» белән шөгыльләнеп килә алмый. Хисамиевның улы Әхмәдуллин да бер атны яхшылап карамыйча яраксыз хәлгә китерә. Тәрбия начар булганлыктан бу колхозда барлык атлар да түбән көрлектә.

«Трактор» колхозының ат караучысы Заһидуллин атларны җәйдән бирле бер генә тапкыр да чистартмаган. Абзарлар пычрак. Бу участокта район җир бүлегенең ветфельдшеры иптәш Манилова эшли. Ләкин ул колхозларга бик сирәк чыга һәм андагы атларның тәрбияләнеше турында бернәрсә дә белми.

Авыл хуҗалыгы артеле үрнәк уставының беренче пунктында атларны яхшы тәрбияләү турында әйтелә. Уставның бу пункты күпчелек колхозларда тупас рәвештә бозыла. Район җир бүлегенең өлкән зоотехнигы иптәш Карабаев үзенең эшенә җавапсыз, гамьсез карый. Менгамьсезлеккә чик куярга вакыт. Язгы кыр эшләрендә тарту көчләре аеруча күп кирәк булачак. Атларны хәзердән үк яхшы тәрбиягә куймаганда, алардан тулысынча файдаланып булмаячак. Шуның өчен, атларны тәрбияләү турында гомумән генә сөйләнеп тормаска, бәлки конкрет эшкә күчәргә вакыт инде.

Ф. МӘҢГӘРЛЕ.

Уку өйләренең эшенә игътибарны көчәйтергә

ЧИСТАЙ. (Телефон буенча). Уку өйләре һәм клублар авылда политик-масса эшен оештыруда һәм алып баруда гаять зур роль уйныйлар. Ләкин Чистай районы колхозларында бу эшкә тиешле әһәмият бирелми. Бары тик 4—5 авылда гына (Тат. Талкыш, Тат. Багана, Нүширмә) аларның эше азмы-күпме юлга салынган.

Районда булган 23 уку өенең 7 се бөтенләй эшләми. Борнаш авыл советы председателе Абрамов, Иске Иванай авыл советы председателе Герасимов иптәшләр уку өйләрен ачу турында, хәтта, уйлап та карамыйлар. Байтирәк авылында уку өенә чәчүлек орлык салганнар. «Победа № 2» колхозында (председателе иптәш Әхмәтҗанов) уку өенә бәрәңге тутырылган.

Уку өе мөдирләренең эше белән районда беркем дә кызыксынмый, аларга алты-шар ай буена хезмәт хакы бирмиләр. Актау авылындагы уку өе мөдире иптәш Донская начар эшләми. Шулай да авыл советы председателе иптәш Кураева аңа 6 ай буена хезмәт хакы бирмәгән.

Халыкны политик агарту эшенең мөһим участы булган уку өйләренә һәм аларның работникларына шундый җансыз карашнәтиҗәсендә, кайбер уку өйләренең җиһазлары һәм әйберләре таркала һәм югала. Мәсәлән, Иске Иванай авылы уку өендәге китапларны кем теләсә шул алып бетергән.

Район мәгариф бүлеге мөдире иптәш Моратов уку өйләренең эшләре белән бөтенләй шөгыльләнми диярлек.

Чистай районы җитәкчеләре уку өйләренең һәм клубларның эшләрен юлга салу өчен кискен чаралар күрергә тиешләр.

Ш. ШАКИРОВ.

„Фронтка концерт"

Шул исемдә кино-фильм эшләп чыгару өчен, Кызыл Армиянең Баш Политуправлениесе һәм СССР Совнаркомы янындагы кинематография эшләре комитеты заданиесе буенча, Казанга махсус кинобригада килде. Бригадага Сталин премиясе лауреаты режиссер И. М. Посельский җитәкчелек итә. Бригада составына кинооператорлардан О. Рейзман, В. Цитрон һәм тавыш операторы М. Соболев иптәшләр керәләр.

Тулы метражлы итеп эшләнә торган бу картинага татар совет сәхнә сәнгатенең барлык төрләреннән үрнәкләр алына. Концертның программасын билгеләү инде тәмамланды инде. Анда татар совет сәнгатенең иң алдынгы артистик көчләре катнашалар. Съемка эшләре шушы көннәрдә башлана. Бу картина героик Кызыл Армиябезнең 25 еллыгы көненә экранга чыгарылган булырга тиеш һәм ул фронтовиклар өчен, аеруча—татар сугышчылары өчен гүзәл бүләкләрнең берсе булачак.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК АЛДЫНГЫЛАРЫ БҮЛӘКЛӘНДЕ

Шушы көннәрдә Арча район җир бүлеге терлекчелек алдынгыларының район киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә колхозларның терлекчелек өлкәсендә 1942 нче елгы эшләре турында доклад ясалды һәм 1943 нче елда терлекчелекне тагын да үстерү буенча практик чаралар билгеләнде.

Терлекчелекне алга җибәрүдә яхшы уңышларга ирешкән работниклар бүләкләнделәр. Алар арасында үзе тәрбияли торган һәрбер сыердан уртача 1.375 литр сөт алып, заданиене 110 процентка үтәгән Әхмәтҗанова (Насыйровка колхозы члены), һәр ана дуңгыздан 10 урынына 18 дуңгыз баласы алып үстергән А. Капонова (Молотов исемендәге колхоз члены), үткән елны колхозга 50 бозау тәрбияләп үстереп биргән Бакаева («Завет Ильича» колхозы члены) һ. б. иптәшләр бар.

Шулай ук һәр умартадан план буенча 30 килограмм урынына 57 килограмм бал алган умартачы Г. Гатауллин (Сталин исемендәге колхоз) да бүләкләнде. Бүләкләнүчеләр арасында «Известия» колхозы умартачысы Разия иптәш Фәттахова да бар. Иптәш Фәттахова колхозга планнан тыш 2.288 килограмм бал җитештереп биргән.

Н. ХӘЙРУЛЛИН.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

Председателе иптәш Мөбарәкшин булган «Кызыл почмак» артеленең колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары Кызыл Армия сугышчылары турында кайгыртучанлык күрсәтүдә Арча районында үрнәк булып торалар. Алар Кызыл Армия фондына шактый гына ашлык һәм башка төрле продуктлар бирделәр. Шушы көннәрдә бу фондка колхозчылар тагын 180 пот ашлык тапшырдылар.

Су баса торган урыннардан барлык йөкләрне вакытында ташырга

Ел саен яз килү белән Волга, Кама һәм Татарстан АССР территориясендәге башка елгалар шактый киңәяләр. Болыннарны һәм уйсу җирләрне, аларда булган аерым биналарны һәм корылмаларны, шулай ук халык яши торган кайбер пунктларны да су баса. Су баса торган урыннардагы йөкләрнең һәм башка материалларның агып китүләренә юл куймас өчен, һәр яз башында әзерлек чаралары үткәрелә.

Быел, сугыш вакыты шартларында, су баса торган урыннардагы йөкләрне, биналарны һәм төрле корылмаларны саклау аеруча зур әһәмиятле урын тота.

Үткән еллардагы тәҗрибәләр күрсәткәнчә, кайбер предприятиеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре, транспорт ягыннан беркадәр кыенлыкка төшүләре сәбәпле, бу әһәмиятле эшне көн саен кичектереп киләләр, су баса торган урыннардагы йөкләрне уңайлырак вакыт килгәннән соң, ташытып бетерергә уйлыйлар. Ләкин мондый «уңайлы вакыт» килеп җиткәндә яз башланә, шунлыктан йөкләрне ташып бетерү өчен гадәттән тыш чаралар күрергә туры килә. Кайчакта мондый йөкләрне, ташытып бетерүне, тәэмин итә ала торган башка оешмаларга бирергә туры килә, нәтиҗәдә йөкләрнең хуҗалары үзләренә кирәкле булган материаллардан мәхрүм булып калалар. Кайчакта гадәттән тыш чаралар да җитми. Суның бик тиз артып китүе сәбәпле агач материалларын, печән, ашлык һәм башка кайбер материалларны коткару өчен аерым экспедицияләр һәм эшче бригадалары оештырырга кирәк булып чыга.

Мондый кыенлыкларның сәбәбе предприятиеләрнең һәм оешмаларның башында утыручы кайбер кешеләрнең эшлексезлекләреннән килә. Алар үткән еллардагы ялгышларны кабатламау өчен үз вакытында бөтен кирәкле чараларны күрмиләр.

Монда шуны әйтергә кирәк: узган көз көнендә мондый оешмаларның һәм предприятиеләрнең күп кенә агач материаллары елгаларда туңып калды. Аларны ашыгыч рәвештә боздан чыгарырга һәм куркынычсыз урыннарга ташып куярга кирәк. Су баса торган урыннарда күп кенә печән һәм башка йөкләр дә бар. Алар да кичекмәстән ташылып куелырга тиеш.

Волга, Кама, Вятка, Агыйдел һәм башка елгалар буенда булган шәһәр һәм район башкарма комитетлары су басуга каршы көрәш комиссияләре төзергә һәм су басуга каршы көрәшүне алдан ук оештырырга тиешләр. Су баса торган урыннардагы барлык йөкләрне кичекмәстән исәпкә алырга һәм 1943 нче елның беренче мартыннан да соңга калмыйча аларның ташылып бетүен тәэмин итәргә кирәк. Су баса торган урыннардан үзләренең йөкләрен вакытында ташытмаган оешмаларның җитәкчеләренә җавапка тартылачаклары турында кисәтү ясалырга тиеш.

Күперләрне саклау эшенә дә зур әһәмият бирергә, күпер баганалары янындагы бозларны үз вакытында ватып агызырга, сүтелмәле күперләрне язгы ташу башланганга кадәр сүтеп куярга, сүтелми торган күперләр өстенә таш өяргә, телеграф, телефон чыбыкларын саклау өчен чаралар күрергә кирәк. Су басу куркынычы булган барлык складлар, кеше тора торган биналар бушатылырга, мондый биналарның аскы катлары су кермәслек итеп томаланырга, ташу вакытында күчерелә торган кешеләр өчен биналар әзерләнергә тиеш.

Язгы ташу башланганчы бу эшләрнең бөтенесен дә тәмам итәргә кирәк. Бу эшләрнең барышы җәмәгатьчелек контроленә алынырга тиеш.

Ф. КОВАЛЬСКИЙ.
Татарстан АССР Совнаркомы председателе урынбасары



АКШ ның кораллы көчләре. Рәсемдә: АКШ ның Төньяк-Көнбатыш өлешендәге сынау танкодромында «Генерал Ли» танклары елга аркылы кичәләр.

ТАСС фотохроникасы.

Вашингтондагы матбугат конференциясендә Рузвельтның чыгышы

ВАШИНГТОН, 3 февраль. (ТАСС). Кичә булып үткән матбугат конференциясендә Рузвельт, Касабланкада булган киңәшмәнең максаты сугышта җиңеп чыгуны тәэмин итү һәм АКШ ның, Англиянең һәм Советлар Союзының Европада кискен удар ясаячаклары турында 6 нчы январьда үзенең конгресска язган хатында биргән вәгъдәләренең үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт булды, дип белдерде. Рузвельт 6 нчы январьдагы хатында үзенең түбәндәгеләрне әйткәнлеген хәтергә төшерде: «Мин алдан әйтеп куя алмыйм. Мин сезгә берләшкән милләтләрнең кайчан һәм кайда Европага чираттагы ударны ясарга җыенганлыкларын әйтә алмыйм, ләкин без нык һәм бик нык кыйнарга җыенабыз. Мин сезгә дошманга ударны Норвегиядән яки Бельгия һәм Голландиядән, Франциядәнме яки Сардиния ашамы, Сицилия яки Балкан ашамы, Польша аша яки бер үк вакытта берничә пункттанмы ясаячагыбызны әйтә алмыйм. Ләкин мин, коры җирдә безнең ударны кайда һәм кайчан ясавыбызга карамастан, —без, англичаннар һәм руслар, дошманны һавадан торып кискен рәвештә һәм туктаусыз кыйнаячагыбызны әйтә алам. Без дошманның хәрби һәм башка предприятиеләренә һәм диңгез портларына шартлаткыч әйберләрне көн саен һәм көн саен, тонна артыннан тонна ташлап торачакбыз». Касабланкадагы киңәшмә,— диде Рузвельт, — АКШ һәм Англия штаблары начальникларының берләшкән группалары аша бу вәгъдәне үтәү максатларында бердәм килешүгә иреште. Конференция, табигый буларак, Сталин белән һәм Чан Кай-ши белән элемтә тотты. Билгеле булганча, диде Рузвельт, кайбер кешеләр, Сталин һәм Чан Кай-ши конференциядә катнашырга тиешләр иде, ләкин Советлар Союзы Япония белән сугыш алып бармый, ә Кытай үзенең географик хәле буенча Германиягә каршы сугыша алмый, дип уйладылар. Рузвельт, бу кешеләр, әгәр дә фактларны җентекләп тикшерсәләр, киләчәктә мондый ялгыш аңлаулардан котылырлар, диде.

Касабланкадагы киңәшмәнең карарлары Советлар Союзына хәбәр ителгәннән соң Сталиннан нинди дә булса җавап алындымы, дигән сораугa Рузвельт раслап җавап бирде. Сталин бу карарлар белән килешәме, дигән сораугa Рузвельт, мондый мәсьәләләрдә ризалыкны да һәм фикер каршылыгын да тикшерү мөмкин түгел, чөнки бу мәсьәләләр бик нык сер итеп саклана̶лар, шул ук вакытта әйтергә кирәк, эшләр бик яхшы баралар. Рузвельт хәбәрчеләргә, Сталин белән булган фикер алышуларның игълан ителергә мөмкин булмаганлыгын барлык эшләр дә яхшыдан тормый икән дигән мәгънәдә аңлатмаска кирәк, дип кисәтте. Рузвельт, эшләрнең бик яхшы рәвештә җәелдерелгәнлегенә тагын бер тапкыр ышандырды. Рузвельт киләчәктә Сталин белән очрашуына өметләнәме, дигән сораугa Рузвельт образлы итеп җавап бирде: «Өмет чыганаклары мәңгелек».

Төньяк Африкадагы политикага кагылган сораугa җавап биреп, Рузвельт, Төньяк Африка проблемасы шактый дәрәҗәдә хәрби проблема булып тора, һәм анда эшләр уңышлы бара, дип җавап бирде. Төньяк Африкада де Голль яклы кешеләрнең де Голльне ачыктан-ачык яклаганлыклары өчен кулга алыналар икән дигән хәбәрне Рузвельт кискен рәвештә юкка чыгарды. Рузвельт, үзенең Жирога карата яхшы фикердә икәнлеген, чөнки Жироның де Голльгә булышлык итүен күрсәтте. Жиро һәм де Голль штаблары арасында фикер каршылыгы тудыруга юнәлдерелгән һәрбер омтылыш дошманга ярдәм итә. Рузвельт, хәзерге вакытта Жиро армиясендә 250.300 кеше барлыкны һәм Жироның күбрәк кораллар сорап мөрәҗәгать иткәнлеген белдерде: Рузвельтның сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Жироны хәзерге заман кораллары белән тәэмин итү чаралары күрелә. Аннары Рузвельт, Жиро белән де Голль арасындагы киңәшмәләрнең зур координацияләргә һәм француз лидерларының һәр икесе арасында хезмәттәшлеккә китерәчәгенә үзенең ышанганлыгын белдерде.

Де Голльнең коралы көчләренә карата куелган сораугa җавап биреп Рузвельт, де Голльнең 15.000 нән 20.000 гә кадәр гаскәрләре барлыкны, шуларның шактый өлеше сахра аша Төньяк Африкага килгәнлеген белдерде. Рузвельт, де Голльнең коралы көчләренең бер өлеше, ихтимал, Мадагаскар районында һәм Яңа Калидониядә торадыр, дип күрсәтте. Рузвельт англичаннарның де Голльне хәзерге заман кораллары белән тәэмин иткәнлекләрен хәбәр итте.

Перутонны билгеләү проблемасын сез Черчилль белән тикшердегезме, дигән сораугa Рузвельт раслап җавап бирде. Төньяк Африкада немецларга каршы сугышырга теләүче элементларның барысын да властьлар азат иттеләрме, дигән сораугa Рузвельт, әгәр дә аларга карата бүтән гаепләүләр ташланмаса, алар барысы да диярлек азат ителделәр, дип җавап бирде.

Үзенең Варгас белән булган киңәшмәсенә тукталып, Рузвельт, бу киңәшмә вакытында тикшерелгән ике иң төп мәсьәлә, су асты көймәләренең һөҗүме куркынычын бетерү буенча Бразилиянең чараларына һәм Көнбатыш ярымшарга Төньяк Африка ягыннан ясалуы мөмкин булган һәртөрле куркынычны бетерү турындагы килешүләргә кагылдылар, дип белдерде. Рузвельт, хәзерге вакытта Кушма штатлардан алынган материаллардан Бразилиянең бик күп эсминецлар төзегәнлеген хәбәр итте. Рузвельт Варгасның Бразилиягә материаллар кертүне арттыруны сораганлыгын күрсәтте һәм Бразилиянең шулай ук су асты көймәләренә каршы көрәш өчен күп санда самолетлар алганлыгын да белдерде.

Төньяк Африкадагы хәл турында Хэллның белдерүе

ВАШИНГТОН, 4 февраль. (ТАСС). АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл үзенең матбугат конференциясендәге чыгышында, Төньяк Африка турындагы мәсьәлә буенча АКШ белән Англия арасында фикер каршылыкларының булмавы турында Иденнең белдерүен котлады. Хэлл, Иденнең бу белдерүе күчәр державаларына каршы көрәштә бердәмлеккә ирешү өчен АКШ ның омтылышларына туры килә, дип күрсәтте.

„РУСЛАР ТАРИХТА ИҢ ЗУР СУГЫШЛАРНЫҢ БЕРСЕН ОТТЫЛАР“

Сталинград янында чолганып алынган дошман гаскәрләрен бетерүнең тәмамлануы турында Америка матбугаты

НЬЮ-ЙОРК, 3 февраль. (ТАСС). Сталинград янында Германия гаскәрләренең соңгы калдыкларын бетерү турындагы хәбәрләр Америкадагы бөтен матбугатның игътибар үзәгендә тора.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгы, Сталинград янындагы көрәшнең сугыш барышында борылыш пункты булуы мөмкин, дип күрсәтә. Монда Германия армиясе чын-чыннан һәлакәткә очрады. Сталинград янындагы сугышлар Германия коралының моңа кадәр күрелмәгән җиңелүе белән тәмам булды. Гитлер бу җиңелүне немецларга берничек тә аңлата алмый. Бу җиңелү Гитлерның «хәрби осталыгының» һәлакәтле икәнлеген күрсәтте. Кызыл Армиянең Сталинград янындагы җиңүләре аны бөек хәрби стратег һәм полководец Сталин җитәкчелек итүнең нәтиҗәсе булып тора. Черчилль Каһирәдәге матбугат конференциясендә Сталинны бөек сугышчы итеп характерлаган иде. Сталинград өчен көрәш дөньядагы иң бөек сугышларның берсе булып тора. Руслар бу сугышта җиңеп чыктылар. Немецлар, Гитлерның дәрәҗәсен саклау өчен, Германиянең 330 мең солдат һәм офицеры корбан ителгәнлекне, әлбәттә, аңлыйлар. Алар шулай ук, русларның Сталин җитәкчелегендә җиңүгә ирешкәнлекләрен, немецлардан өстен булып чыкканлыкларын һәм зур хәрби мастерлык күрсәткәнлекләрен күрми кала алмыйлар. Сталинград янындагы сугышларның нәтиҗәсе, диелә агентлыкның белдерүендә, немецларның йөрәгенә курку салырга тиеш.

„Сталинград русларның батырлыгы турында нур чәчүче мәңгелек һәйкәл булачак“

Кызыл Армиянең Сталинград янындагы җиңүләре турында Швеция матбугаты

СТОКҺОЛЬМ, 4 февраль. (ТАСС). Сталинград янында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренең тар-мар ителүе һәм юк ителүе турындагы мәсьәләгә Швеция газеталары үзләренең баш мәкаләләрен багышлыйлар. «Арбетарен» газетасы үзенең баш мәкаләсендә болай дип яза: «Сталинград янындагы сугышлар вакытында рус солдатларының һәм эшчеләренең чиксез кыюлыгын һәм батырлыгын бөтен дөнья күреп торды. Алар хәзерге бөтен дөнья сугышында гитлерчыларга иң зур сизелерлек удар ясадылар. Сталинград янындагы далаларда немецларның югалтулары аларның көчләрен сындырды. Хәзер немецлар Волгадан ерак торалар һәм русларны җиңүдән алар тагын да ераграк торалар».

«Стокһольмс тиднинген» газетасы үзенең баш мәкаләсендә болай дип яза: «Сталинград аңа һөҗүм итүче һәм аны камап торучы немецлар өчен дә, шулай ук шәһәрне саклаучылар өчен дә гаять зур әһәмияткә ия булды. Бу шәһәрнең исеме русларның батырлыгы турында нур чәчүче мәңгелек һәйкәл булачак. Русларны бик каты ударлар да җиңә алмады. Сталинград янында немецларны тар-мар итүнең руслар өчен гаять зур әһәмияте бар. Волга яңадан иркенләп ага. Үзенең тиңдәше булмаган бу җиңү нәтиҗәсендә Кызыл Армиянең дәрәҗәсе тагын да күтәрелде».

СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ СТАЛИНГРАД ЯНЫНДАГЫ ҖИҢҮЛӘРЕ ТУРЫНДА ХЭЛЛНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ВАШИНГТОН, 4 февраль. (ТАСС). АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл, Сталинград янында Германия гаскәрләренең тулысынча юк ителүләре турындагы хәбәр барлык берләшкән илләргә гаять зур канәгатьләнү бирә, дип белдерде. Сталинград янында гүзәл җиңүгә ирешелде. Бу җиңүгә хәзерге сугыштагы кайсы гына армиягә караганда да үзенең сугышчан сыйфатлары югары булган армия тарафыннан ирешелде.

Сталинград янындагы җиңү—ул, рус коралы көчләренең гүзәл сугышчан сыйфатларының бөек демонстрациясе.

ТӨНЬЯК АФРИКАДАГЫ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 4 февраль. (ТАСС). Англиянең Якын Көнчыгыштагы көчләре командованиесенең белдерүендә, Британия гаскәрләренең 2 нче февральдә Зуарадан көнбатышка таба яр буе секторындагы Зельтен пунктын алганлыклары һәм дошманның чигенүче гаскәрләре белән очрашканлыклары күрсәтелә.

Рейтер агентлыгы 8 нче армиянең Туниста Матмат янындагы Марета линияләренә барып җиткәнлеген хәбәр итә.

Гафстан Макнасига бара торган юл белән һәм Урта диңгез ярына таба бара торган Америка частьлары дошман коммуникацияләренә җитди куркыныч тудыралар.

Союзникларның Төньяк Африкадагы штабыннан хәбәр итүләренә караганда, Тунистагы хәрби операцияләр башланганнан бирле союзниклар авиациясе дошманның 500 самолетын атып төшергән. Шул ук вакыт эчендә союзниклар 200 машина югалтканнар.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ГАМБУРГКА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 4 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Англия авиациясенең 4 нче февральгә каршы төндә Гомбургны көчле рәвештә бомбага тотканлыгын хәбәр итә. Германиянең су асты көймәләре төзүче иң зур верфьләре бомбага тотылган. 16 бомбардировщик үз базаларына кайтмаган.

МАРСЕЛЬДӘ ХАЛЫК ЧУАЛЫШЛАРЫ

НЬЮ-ЙОРК, 4 февраль. (ТАСС). «Нью-Йорк таймс» газетасының Берндагы хәбәрчесенең белдерүенчә, Германия артиллериясе Марсельнең иске порты районындагы торак йортлар кварталларын методик рәвештә җимертүне дәвам иттерә. Гитлерчыларның кыргый ерткычлыгы Марсель халкы арасында гаять зур ризасызлык тудыра. Гестапоның террорына да карамастан, шәһәрдә гитлерчыларның варварларча хәрәкәтләренә каршы стихияле демонстрацияләр өзлексез булып тора.

АНГЛИЯ САМОЛЕТЛАРЫНЫҢ АБВЕЛЬГӘ ҺӘМ СЕНТ-ОМЕРГА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 4 февраль. (ТАСС). Англиянең авиация министрлыгы белдерүендә, 3 нче февральдә көндез Англия бомбардировщикларының Абвельдәге тимер юл корылмаларына һәм дошманның Сент-Омердагы аэродромына һөҗүм ясаганлыклары әйтелә.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 7 нче февральдә—*„Ильдар“*. 8 нче февральдә—*„Чио-Чио-Сан“*.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген — *„Таймасовлар“*. 10 сәгать 30 минутта *танецлар кичәсе*.

Зур драма театры. Бүген — һәм 7 нче февральдә көндез һәм кич—*„Фельдмаршал Кутузов“*.

Яшь тамашачылар театры. Бүген—*„Скосыревлар семьясы“* („Фронт“)

Татар дәүләт филармониясе Менжинский исемендәге клубта бүген яшьләр өчен *зур концерт*. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

Дәүләт циркы. Бүген—*зур цирк тамашасы* һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — музыкаль комедия *„Антоша Рыбкин“*.

„Унион“—*„Котовский“*.

„Пионер“ көндез һәм кич — *3 нче номерлы кино-сборник*.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 75—14, типография 36—60.

ПФ 635 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 213